| | |
|---|---|
| СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| Р Е Ш Е Н И Е | К А Р А Р |
| 2021 елның 1 апрелennән | № 21 |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 1 июнендәге 35 номерлы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча 2021 елның 3 маенда 11 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тойгуҗа авыл җирлеге, Тойгуҗа авылы, Үзәк ур., 48 йорт, (авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карары проекты белән таныштырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Тойгуҗа авыл җирлеге, Тойгуҗа авылы, Үзәк ур., 48 йорт, (авыл мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А. Сафин

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге
Советының
2021 елның 1 апреленнән
21 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Сафин Рафит Әхмәтшин улы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе;
2. Секретарь: Батыршина Роза Илдус кызы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
3. Комиссия әгъзасы: Хабибрахимов Рудик – Тойгуҗа авыл җирлеге Советы депутаты;
4. Комиссия әгъзасы: Гайфетдинова Гөлнара Гыйният кызы – Тойгуҗа авыл җирлеге Советы депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.